ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.09.2023 Балык Бистәсе штп. № 310пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзерлек хәлендә тоту турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына,Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм аларны әзерлек хәлендә тоту турында» 2017 елның 15 июлендәге 496 номерлы карары, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын куллануга даими әзерлек чараларын гамәлгә ашыру, халыкны хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында барлыкка килгән куркынычлардан саклауны тәэмин итү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләре турында нигезләмәне расларга.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдырганда оешма җитәкчеләренә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Нигезләмә буенча эш итәргә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы” нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы

буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 08.09.2023 №310 пи карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы көчләре турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Нигезләмә «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 декабрендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында» 2023 елның 06 сентябрендәге 196пг номерлы карары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы (алга таба-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы) территориясендә гражданнар оборонасы көчләрен булдыру, аның составын, төп бурычларын, куллану тәртибен, шулай ук әзерлек хәлендә тотуны билгели.

### 2. Гражданнар оборонасы көчләре

Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча коткару хезмәтләре рәвешендә гражданнар оборонасы көчләре төзелә.

### 3. Гражданнар оборонасы көчләренең төп бурычлары

Гражданнар оборонасы көчләренең төп бурычлары булып:

Гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итү буенча махсус чараларны үтәү;

хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә халык өчен куркынычлар барлыкка килгән очракта, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрүне тәэмин итү;

хәрби конфликтларда яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкны беренче

чиратта тормыш шартлары белән тәэмин итү;

Гражданнар оборонасы өлкәсендә башка махсус чаралар.

## 4. Гражданнар оборонасы көчләрен оештыру тәртибе

Гражданнар оборонасы көчләрен булдыру тәртибе Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында»2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы белән билгеләнә.

## 5. Гражданнар оборонасы көчләрен куллану

5.1. Гражданнар оборонасы көчләрен куллану Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Гражданнар оборонасы җитәкчесе карары буенча гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәү өчен гамәлгә ашырыла.

Гражданнар оборонасы көчләре тыныч вакытта табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларында катнашу өчен җәлеп ителергә мөмкин.

Тыныч вакытта гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турында карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Гражданнар оборонасы җитәкчесе Балык Бистәсе муниципаль районының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча эш планы нигезендә кабул итә

5.2. Гражданнар оборонасы көчләрен куллануны планлаштыру алдан, аларны булдыру этабында башкарыла.

## 6. Гражданнар оборонасы көчләрен әзерлек хәлендә тоту

6.1. Гражданнар оборонасы көчләрен әзерлек хәлендә тоту тәэмин ителә:

әлеге Нигеләмәнең 3 бүлегендә билгеләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итүче дәрәҗәсендә шәхси составны әзерләү;

махсус техниканы, җиһазларны, коралларны һәм материалларны төзек хәлдә тоту;

оператив әзерлек дәресләрен һәм чараларын (тренировкалар, өйрәнүләр) планлаштыру һәм үткәрү.

6.2. Гражданнар оборонасы көчләренең шәхси составын әзерләү Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының законнар һәм башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать афәтләре нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының идарә органнарын, Гражданнар оборонасы көчләрен һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасын әзерләү буенча, шулай ук Россия

Федерациясе халкын әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләре, гражданнар оборонасы өлкәсендәге федерацияләр, гадәттән тыш хәлләрдән саклану, су объектларында янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, гражданнар оборонасы көчләрен булдыручы оешмаларның документлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.3. Гражданнар оборонасы көчләренең әзерлеген контрольдә тоту Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге төп чаралар планы нигезендә гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм оешмалары белән команда-штаб өйрәнүләре һәм күнегүләр;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итү буенча территориаль штаттан тыш формированиеләр белән тактик-махсус өйрәнүләр;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы коткару хезмәтләре белән махсус өйрәнүләр.

## 7. Гражданнар оборонасы көчләренең эшчәнлеген тәэмин итү

7.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Гражданнар оборонасы көчләрен булдыру, әзерләү, җиһазлау һәм куллану буенча чараларны финанслау аларны булдыручы оешмаларның финанс чаралары хисабына, «Гражданнар оборонасы турында»1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып башкарыла.

7.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә төзелә торган гражданнар оборонасы көчләрен җиһазландыру өчен билгеләнгән матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чараларны туплау, саклау һәм куллану «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын гражданнар оборонасы максатларында туплау, саклау һәм куллану турында» 2000 елның 27 апрелендәге 379 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру турында»2014 елның 06 февралендәге 65 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.